КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 1 август г.Казань № 739

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Наркотикларга каршы өлкәдә проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган социаль юнәлешле оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан конкурс нигезендә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 18 сентябрь, 879 нчы карары белән расланган Наркотикларга каршы өлкәдә проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган социаль юнәлешле оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан конкурс нигезендә субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Наркотикларга каршы өлкәдә проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган социаль юнәлешле оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан конкурс нигезендә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 18 сентябрь, 879 нчы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 14 декабрь, 1228 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Наркотикларга каршы өлкәдә проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган социаль юнәлешле оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан конкурс нигезендә субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктның тугызынчы абзацында «максатчан» сүзен «нәтиҗәле» сүзенә алмаштырырга.

5 пунктның унынчы абзацында «максатлары,» сүзен төшереп калдырырга;

16 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«конкурста катнашучы экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә

массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмаска тиеш.»;

32 пунктның өченче абзацында:

«шулай ук әлеге акчаларны бирү максатларына ирешүгә бәйле башка операцияләр» сүзләрен төшереп калдырырга;

«субсидия алучының, шулай ук устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында гавами-хокукый берәмлекләр, шулай ук устав (тупланма) капиталларында шундый ширкәтләр һәм җәмгыятьләр катнашында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында субсидияләр (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләрдән, хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләрдән тыш) субсидияләр алучы белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның аларга карата субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшерүләрне дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан гамәлгә ашыруга ризалыгы» сүзләрен «субсидия алучының, субсидияләр алучылар белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акчалар алучы затларның (устав (тупланма) капиталларында, коммерция оешмалары катнашында аларның устав (җыелма) капиталларында һәм устав (тупланма) капиталларында дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән тыш) аларга карата Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәүне, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, субсидияләр бирү тәртибен һәм шартларын, шулай ук субсидия алучы тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан тикшерү үтәүне тикшерүгә ризалыгы» сүзләренә алмаштырырга;

37 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«37. Министрлык субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра, ә дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.»;

беренче абзацтан соң түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Министрлык, субсидия бирү турында шартнамәдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны төгәлләү фактын чагылдыра торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүгә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча мониторинг үткәрә.»;

42 пунктта «максатчан һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

16 пунктның өченче абзацының гамәлдә булуын 2023 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

37 пунктның икенче абзацының гамәлдә булуы 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин